# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**28 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 28 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләренә таянып, түбәндәге мәсьәлә буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Киртәле авылында урамнарны яктырту максатыннан энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру;
- Киртәле авылындагы К.Маркс урамындагы юлларны төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 298 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 150кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Киртәле авылында урамнарны яктырту максатыннан энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру;
- Киртәле авылындагы К.Маркс урамындагы юлларны төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.Г. Абмаева**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Киртәле авыл җирлеге башлыгы** **А.Г. Абмаева**